Туган телем – татар теле

# Минем уенчыкларым

(6 нчы дәрес)

# Минем уенчыкларым



- *Камилә, синең уенчыкларың бармы?*
- *Иң яраткан уенчыгың нинди?*

**Минем кызым – курчагым**

Әй акыллы курчагым,
Йом күзеңне бәлли-бәү.
Башка бер сүз дә дәшмим,
Йоклап алыйк без икәү.

*(Җәвад Тәрҗеманов)*

# Куянкай

Әй, куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына,
Бик куркак кына.

Ике колагы
Озынкай гына.
Аягы җиңел –
Мамыктай гына.

*(Нәкый Исәнбәт)*



# Туп

Әминә елый үкереп,

- Тубым суга төште, - дип.

- Чү, Әминә, елама:

Туп батмый ул елгада.

*(Әминә Бикчәнтәева)*



# Уенчыклар



Без уйныйбыз залда,
Ни генә юк анда:
Тун кигән аюлар,
Кыланчык маймыллар,
Тиеннәр, керпеләр,
Куяннар, төлкеләр,
Мөгезле пошилар,
Мыеклы песиләр,
Әтәчләр, тавыклар,
Кәҗәләр, сарыклар...

*(Бари Рәхмәт)*

# Әнигә булышам

Бик зур үстем инде мин,
Әнигә булышам.
Үз ботинкамны үзем
Кияргә тырышам.

Әниемнең эше күп:
Бәйли миңа оек.
Бүген бөтен уенчыкны
Үзем куйдым җыеп...

*(Газиз Нәбиуллин)*



# Уйныйбыз!

Очты, очты – каргалар очты.

Очты, очты – чыпчыклар очты.

Очты, очты – курчаклар очты.

Очты, очты – үрдәкләр очты.

Очты, очты – казлар очты.

Очты, очты – тазлар очты.

Очты, очты – тавыклар очты.

Очты, очты – самолётлар очты.

# Табышмак

Минем белән уйныйлар,
Кулларыннан куймыйлар,
Иркәлиләр, сөяләр,
Йокла, бәбкәм, дияләр.
Үсә төшкәч, балалар
Мине онытып калалар.

*(Курчак)*



# Физкультминут

**Матур тубым**

Минем тубым бигрәк җитез: *(кулларын чәбәклиләр)*

Матур итеп сикерә. *(сикерәләр)*

Әгәр тотып өлгермәсәң, *(кулларын өскә күтәрәләр)*

Әллә кая йөгерә. *(бер урында йөгерәләр)*



Дәрес тәмам, дуслар!
Сау булыгыз!